**Горурланырлык ирләребез**

# Татар милләтенең арысланы



Татар халкының мәдәни, милли, сәяси тормышында зур роль уйнаган милли хәрәкәт лидерлары, идеологлары, милли хәрәкәт эшлеклеләре арасында үзенең бар гомерен татар халкына, мөселман халыкларына хезмәт итүгә багышлаган Садри Максуди да бар. XX йөз башы татар дөньясында татар милли мәгарифен яңача үзгәртеп коруга, дини эшләрен реформалаштыруга, вакытлы татар матбугатын барлыкка китерүгә, гомумән, шулар аша халыкның милли аңын үстереп, милли горурлыгын уятып, татар халкының югалткан дәүләтчелеген торгызуга омтылган милли хәрәкәт барлыкка килә. Садри Максуди - татар милли хәрәкәтенең төп идеологларының берсе буларак, үзенең белеме, сәяси кыйбласы, Русия сәясәтендә тоткан урыны һәм эшләгән эшләре белән милли хәрәкәттә башкалардан шактый аерылып торган шәхес.

### Мостафа Кемалның киңәшчесе

Шулай ук ул татар халкы тарихында Эчке Русия һәм себер төрек-татарларының Милли-мәдәни V мохтарияте рәисе буларак, ягъни хәзергечә әйткәндә, президенты буларак та кереп калса, Төркия Республикасы тарихына исә олуг галим, Төркия Бөек Милләт мәҗлесенең өч чакырылыш Милләт вәкиле, Төркия президенты Мостафа Кемалның Киңәшчесе һәм 1954 елда президентлыкка кандидат буларак (кандидатурасын үзе ала) кереп калган шәхес тә әле. Мондый биеклеккә 1918 елдан соң Россиядән эмиграциягә киткән бер генә танылган сәясәтче дә ирешә алмаган. Бер шәхеснең - сәясәтченең ике илдә - ике дәүләттә президентлыкка сайлануы XX гасыр тарихында уникаль очрак.

### Татарстанның игелекле углы

Садри Максуди (Садретдин Низаметдин улы Максудов) 1878 елның 23 июлендә (иске стиль белән) Татарстанның Ташсу авылында (хәзерге Биектау районына керә) Низаметдин мулла гаиләсендә дүртенче бала булып дөньяга килә.

### Садри алты телдә сөйләшкән

Бу гаиләдә белемгә омтылыш көчле була, чөнки үз заманының шактый укымышлы кешесе буларак, Низаметдин мулла Төркиядән төрле гәҗит-журналлар, китаплар кайтарткалап торган. Шуннан кайткан төрек әлифбасыннан Садри укырга өйрәнә. Ул башта үз авыллары мәдрәсәсендә - әтисендә укый, аннан Казанда абыйсы Әхмәтһади мөгаллимлек иткән Галләмия мәдрәсәсендә белем ала. Биредә ул сигез ел буена төрек, гарәп, фарсы телләрен, Ислам фәлсәфәсен, дин белемнәрен өйрәнә. Ләкин, тора-бара, абыйсы Һади өендәге төрекчә китап-журналлар, «Тәрҗеман» гәҗите генә яңалыкка сусаган һәм кызыксынучан табигатьле яшүсмер егетне инде канәгатьләндерми башлый: ул үзлегеннән урысча өйрәнергә керешә.

### Садри Максуди Гаспринский белән таныша

Садриның аннан ун яшькә өлкәнрәк булган абыйсы Әхмәдһади төрки дөньяда беренче гәҗит - «Тәрҗеман» гәҗитен чыгара башлап, үз гәҗите битләрендә төрки халыкларда миллият хисләрен уятучы беренче орлыкларны чәчәргә керешкән атаклы Исмәгыйль бәк Гаспринский белән дустанә мөнәсәбәтләрдә була. И.Гаспринский аны Бакчасарайга Зынҗырлы мәдрәсәсенә укытучы итеп чакыргач, Һади Максуди шатланып риза була һәм үзенә ияртеп, энесе Садретдинны да Кырымга алып китә. Биредә ул төрек телен, тарих, география, табигать белемен өйрәнә. Садретдинның Кырымга килүе һәм анда Исмәгыйль бәк Гаспринский белән танышуы яшь егетнең киләчәгенә төп юлны билгеләгән һәм аның тормышында иң зур әһәмияткә ия вакыйга булган.

### Төрки халыклар бердәм булганда гына уңышка ирешеп була

Яшүсмер Садри үзенең яшьтәшләренә караганда укымышлырак була, һәм нәкъ менә шушы ягы белән ул Исмәгыйль бәкнең игътибарын җәлеп итә. Ә яшь Садрига аның бер фикере ошый, ул - төрки халыкларның берлеге, бердәмлеге турындагы фикер. Исмәгыйль бәк Гаспринский, һәр форсаттан файдаланып, бөтен төрки халыкларның бер гаилә, ягъни Кырым һәм Казан татарларының, башкорт, кыргызларның бертуган булуы, христиан динендәге чуаш, шаман булган якутларның да бер төрки гаилә әгъзалары икәнлекләрен Садрига җентекләп аңлата. Шул ук вакытта Исмәгыйль бәк Гаспринский Казан татарларының иң мәдәниятле халык булулары аркасында үзләрен башкалардан югары тотулары, үзләрен өстен куюларын тәнкыйть итеп, ачынып сөйли һәм яшь Садрида моны бетерү өчен, аңа бөтен төрки халыклар бердәм булганда гына тәрәккыят юлында уңышларга ирешеп булачагын аңлатырга тырыша.

Бер елга якын бергә аралашып яшәүнең файдасы була: яшь Садри Максуди төрки бердәмлек, халык язмышы турында уйлана башлый. Аңарда бөек төркиче Исмәгыйль бәк Гаспринскийга карата тирән ихтирам һәм аркадашлык хисләре уяна. Һәм, еллар узгач, ул тормышының һәр хәлиткеч борылышында Исмәгыйль бәк Гаспринскийның милләт хисе һәм төрки бердәмлек турындагы сүзләрен исенә төшерә, кызы Гадилә Айда әйтүенчә, «Минем рухи атам - Исмәгыйль бәк Гаспринский» дия торган була. Шунысы да хак: Исмәгыйль бәк Гаспринский Садри Максудиның милләткә хезмәт итүдәге тоткан кыйбласына озак еллар юнәлеш биреп торучы да әле ул.

### Күңелсез хәбәр

Ләкин Зынҗырлы мәдрәсәсендә белем эстәп яткан вакытта, 1894 елны Ташсудан күңелсез хәбәр килә: аталары Низаметдин мулла авырый башлаган. Агалы-энеле Максудилар Казанга кайтып китәргә мәҗбүр булалар.

### Садри Максуди 19 яшендә беренче татар романын язучы

Казанга кайткач, Садри Галләмия мәдрәсәсен тәмамлый һәм Учительская школага укырга керергә карар итә. Бәхетенә, аның бу теләгенә гаиләсе дә каршы килми, абыйсы Һади да аны хуплый. Биредә укыганда Садри тулысынча рус әдәбияты һәм рус теленә тәрҗемә ителгән фәнни әдәбият дөньясына чума. Үзе укыган рус романнары тәэсирендә татарча «Мәгыйшәт» исемле роман да яза. Бу беренче татарча милли роман була, роман 1898 елда басылып та чыга. Ә бит С.Максудига бу вакытта барысы тик унтугыз яшь кенә була, әмма шуңа да карамастан, «Мәгыйшәт» романына инде киләчәктә С.Максуди үзе шуларны хәл итүгә бар гомерен багышлаячак проблемаларның күбесе салынган. Муса Акъегет, Заһир Бигиев романнары югарылыгында язылган әлеге әсәр «алар иҗатында билгеләнгән казанышларның дәвамы, үстерелеше, яңа югарылыкларга омтылышы булып тора».

### Татар милләтенең киләчәккә юлын күрсәткән роман

«Мәгыйшәт» романының 1914 елда басылып чыккан икенче басмасына кереш сүзендә Садри Максуди үзе болай дип язган: «Мәгыйшәт» реалист юлда язылса да, фикер тарату максаты белән, укучыда «әмәл» тудыру фикере белән язылган бер әсәрдер». Ул үзенең әлеге романында күтәрелгән проблемалар аша татар милләтенең киләчәккә юлын күрсәтергә, татар укучысын үзенең бүгенгесе, киләчәге хакында уйланырга чакырган, дисәк тә ялгыш булмас.

### Урыс университеты татар өчен ябык

Учительская школада укыган елларда Садрида француз телен өйрәнү теләге туа. Шунлыктан ул, сабакташлары йокларга яткач, русча тәрҗемә ителгән Руссо кебек философларның әсәрләрен, Мольер пьесаларын, фәнни әдәбиятны да зур кызыксыну белән төннәр буе укып утыра. Ул вакыттагы Россиядә француз әдәбияты, француз мәдәнияты белән кызыксыну көчле була, шунлыктан ерак Франция, үзе әсәрләнеп, мавыгып укыган серле Париж Садри Максудида Франциягә барып уку теләген уята. Әмма ул бу уй-хисләрен хәтта абыйсы Һадидан да яшерә, чөнки аңа үзенең бу теләге тормышка ашмас хыял гына булып тоела. 1901 елны Учительская школаны тәмамлагач, С.Максуди университетка кермәкче булып, Петербургка бара. Тик урыс университетының ишекләре татар баласы өчен ябык була.

### Садри Лев Толстой белән очраша

Садри Ясная Полянага барып, үзе һәр әсәрен яратып укыган һәм бик хөрмәт иткән Л.Н.Толстой белән очраша, анда бер көн була. С.Максуди үзенең Толстой белән очрашып-сөйләшеп уздырган вакытын «гомеренең иң гүзәл мизгелен»нән саный.

### Садри кабат Кырымга китә

Аннан ул Кырымга китә, анда Исмәгыйль бәк Гаспринский белән күрешә, үзенең белемен дәвам итәр өчен Төркиягә китәргә теләвен әйтә. Әмма И. Гаспринский аңа ул вакытта Европа мәдәниятенең мәркәзе булган Парижга китәргә, укуын шунда дәвам итәргә тәкъдим итә. Исмәгыйль бәк Гаспринскийның бу тәкъдименнән соң, күңеленең иң тирән җиренә яшерелгән Парижга барып уку теләге Садрида яңадан кабынып китә. «Ара-тирә «Тәрҗеман»га мәкаләләр язарсың, мин дә сиңа җибәргәләрмен, сине ач тотмабыз», дип, ул С.Максудиның бу сәфәренә үзенең хәер-фатыйхасын бирә.

**(Дәвамы бар)**

**Мәгълүматны Шамил БАҺАУТДИН туплады.**

**Юмарт ирләребез**

# «Яктылык» мәктәбенә футбол кыры бүләк иттеләр

**Самардагы «Торгиндустрия» ширкәте Самарның «Яктылык» мәктәбенә өч миллион сумлык футбол кыры бүләк итте. Мәктәп йортының бер читендә мәктәп нормативына туры китереп, ясалма үлән җәйделәр, биек-биек тимер челтәрдән коймалар тоттылар. Мондый футбол кыры — Самар мәктәпләрендә бик сирәк күренеш. Саный башласаң, бер кулдагы бармаклар да җитә.**

Ширкәтнең мөдире утыз ике яшьлек Фәрид углы Әлмир Мөхтәров. Әлмир әфәнде классик ирләрне хәтерләтә. Микрофон кабызырга рөхсәт бирмәде. Аз сүзле. Тыйнак.

«Самарда туып-үстем. Изге Корбан аенда күңелләр нечкәрә. Изгелек эшлисе килә. Балаларны куандырудан да зур шатлык юк бит», - диде Әлмир әфәнде.

Әлмир Мөхтәров үзе белән һөнәрмәнд футболчыларны да алып килгән иде. Мәктәп егетләре белән футбол уйнап, алар әле мастер-класс та биреп киттеләр.

Мәктәпнең тарихы унбиш елга сыя. Тарих өчен мизгел булып саналган шул елларда мәктәп мөдире булып Харидә Дашкина һәм Дания Әбдрәхимовалар эшләде. Быелгы уку елыннан башлап бу вазыйфаны Радик Газизов башкара. Яңа мөдир мәктәп тарихына бик зур яңалык белән аяк басты. Хөрмәткә лаек. һәр нәрсә чагыштыруда билгеләнә. Хәтта Самарның атаклы 41нче мәктәбендә дә ясалма үлән җәелгән футбол кыры юк.

Радик Газизов әйтүенчә, Самар татар эшбатырлары мәктәп мөнфәгатьләрен аңлап, ярдәмнәреннән ташламыйлар икән.

Шул ук вакытта «Яктылык» мәктәбен дәүләт бабай да кыерсытмый. Самар шәһәр мәгариф департаменты әле генә 300 мең сум акча биреп, мәктәпнең түбәсен яптырган.

Самар өлкә мәгариф министрлыгы 19 ноутбук биргән. Заманча теннис өстәле алган. Татар көрәше өчен җиһазлар булдырган.

«Татар этнокомпоненты булган «Яктылык» белем йортына хөрмәт белән карыйлар», - ди мөдир.

Бу хөрмәт тантанага килгән шәхесләрдән дә күренеп торды. Район администрациясенең яшьләр бүлеге хезмәткәре Александр Панкратов, Самар шәһәр мәгариф департаменты белгече Елена Каракулова мәктәп турында тик изге сүзләр генә яңгыраттылар. Самар шәһәр Думасы исеменнән килгән Алсу Сәләймәнова Мактаунамәләр тапшырды.

**«Яктылык»ны мактап, үз балаларын урыс мәктәбенә ташыган милли юлбашчылар буа буарлык. Ә менә Самар шәһәр милли-мәдәни мохтарияте рәисе Рифкат Хуҗин бер кызын шул мәктәптә укытып, югары белем бирә алды. Хәзер икенче кызы «Яктылык»ны тәмамлый. Шуңа да аның чыгышында бер генә дә ясалмалык булмады.**

Мәктәптә сирәк-мирәк булса да, казах, кыргыз, үзбәк һәм башка милләт балалары да белем ала. Ләкин дә барчасы да татарча бииләр, татарча җырлыйлар, татарча сөйләшәләр. Миһербанлык һәм изгелек сыйфатлары нарасыйларның йөзенә чыккан. Укучыларны татар гореф-гадәтләренә, динебез Ислам таләпләренә таянып тәрбиялиләр, чөнки укытучылар үзләре шул сыйфатларга ия. Заманында мин бер урыс түрәсеннән ишеткән идем: «Дети «Яктылык» - это штучный товар». Хак сүзләр, чөнки мондагы мөгаллимәләр балаларга белем дә бирәләр, шул ук вакытта алар балаларның сердәшчеләре дә әле.

***Шамил БАҺАУТДИН.***